КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 март г.Казань № 230

Югары белем бирүче «Яр Чаллы дәүләт сәүдә-технология институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе – белем бирү оешмасы тибын һәм аның исемен «Яр Чаллы технология техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе итеп үзгәртү турында

Татарстан Республикасының югары белем бирүче мәгариф оешмалары челтәрен оптимальләштерү, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр һәм урта звено белгечләрен әзерләү сыйфатын яхшырту максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының югары белем бирүче «Яр Чаллы дәүләт сәүдә-технология институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе – белем бирү оешмасы (алга таба – Яр Чаллы дәүләт сәүдә-технология институты) тибын һәм аның исемен «Яр Чаллы технология техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба – Яр Чаллы технология техникумы) итеп үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Яр Чаллы технология техникумын гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

Яр Чаллы дәүләт сәүдә-технология институтында белем алучыларны аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, Яр Чаллы дәүләт сәүдә-технология институтында гамәлдә булган урта һөнәри белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем бирү шартларын һәм программаларын саклап, Яр Чаллы технология техникумына күчерергә;

30 көн эчендә:

Яр Чаллы дәүләт сәүдә-технология институтының Яр Чаллы технология техникумына кирәк булмаган мөлкәт исемлеген, шулай ук аларны алга таба

файдалану турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

ел саен Яр Чаллы технология техникумы өчен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен расларга;

Яр Чаллы технология техникумында белем алучыларны әзерләү алып барылачак белгечлекләр исемлеген билгеләргә;

60 көн эчендә Яр Чаллы дәүләт сәүдә-технология институты уставына үзгәрешләр кертергә.

3. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә һәм «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге ТРЗ-88 номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү хакындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә кертергә.

4. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, бу карарның 2 нче, 3 нче пунктларын үтәгәннән соң бер ай эчендә Татарстан Республикасының тиешле норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

6. Бу карар 2019 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин